Ситдыйкова, Ә. Гамь галәмен кичеп : Язучы һәм шагыйрь Факил Сафинга: шигырь / Ә. Ситдыйкова. – Текст: турыдан-туры, электрон // Мәдәни җомга. – 2024. – №48 (6 декабрь). – Б. 7. – URL: https://madanizhomga.ru/news/kykregemde-shigyir-utyim-saumyi/alfiia-sitdyikova-gam-galamen-kicep-atlyi-sagyir-kulga-totyp-kainar-ioragen. – Чыгу вакыты: 07.12.2024



## ГАМЬ ГАЛӘМЕН КИЧЕП

*Язучы һәм шагыйрь Факил Сафинга*

Һәр сандугач таба кунып сайрар
Зифа талын, күңел тирәген.
Гамь галәмен кичеп атлый шагыйрь,
Кулга тотып кайнар йөрәген.

Йодрык кадәр йөрәгенә сыйган
Дөньяның бар борчу, шатлыгы.
Сәфәр чыккан әдип үргә менә,
Юлдаш аңа күңел аклыгы.

Иҗат чишмәсенең суы мулдан,
Күпме җанны пакъли, сугара.
Яши яңа ачыш,  табыш белән
Бизәк өстәп узган елларга.